СОВЕТ МАЛОЛЫЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ ЛЫЗИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
« 29 » ноябрь 2024 г.

**КАРАР**
№ 118

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында
Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Гамәлдәге кануннарга туры китерү максатында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Кече Лызи авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Кече Лызи авыл җирлеге Советы 26.04.2021 елынының 19 нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Кече Лызи авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статьяның 3 пунктына «яисә яллаучы (эш бирүче) вәкиле вазыйфаларын башкарырга вәкаләтле башка зат» сүзләрен өстәргә;

1.2. 9 статьяның 6.1 пунктында икенче җөмләне төшереп калдырырга;

1.3. 9 статьяның 10 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

1.4. 9 статьяның 13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Муниципаль хезмәткәргә класслы чин бирү турындагы карар,әлеге статьяның 7 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарәнең класслы чиннар бирергә вәкаләтле органына яисә вазыйфаи затына барлык кирәкле документлар белән класслы чин бирү турында тәкъдим кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.»;

1.5. 14 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12 пунктча өстәргә:

«12) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) әлеге Нигезләмәнең 15.2 статьясында каралган анкетадагы белешмәләрнең үзенә мәгълүм булган үзгәрешләр турында язма рәвештә хәбәр итәргә, моңа яллаучы (эш бирүче) вәкиленең карары буенча үзгәргән белешмәләр (алга таба - анкетадагы белешмәләр) керми.»;

1.6. 3 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 15.2 статья өстәргә:

«15.2 статья. Анкета тапшыру, анкетадагы белешмәләрне үзгәртү турында хәбәр итү һәм мондый белешмәләрне тикшерү

1. Муниципаль хезмәткә кергәндә гражданин анкета тапшыра.

2. Муниципаль хезмәткәр яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) анкетада булган белешмәләрнең мәгълүм үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итә.

3. Анкетаның рәвеше, шул исәптән аңа кертелә торган белешмәләрнең исемлеге, тәртибе һәм аларны актуальләштерү сроклары Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләнә.

4. Анкетадагы белешмәләр яллаучы (эш бирүче) вәкиленең яисә ул вәкаләт биргән затның карары буенча тикшерелергә мөмкин. Анкетада булган белешмәләрне тикшерү тиешле мәгълүматка ия булган оешмаларга һәм гавами хакимият органнарына язма рәвештә соратулар, шул исәптән дәүләт мәгълүмат системалары ярдәмендә җибәрү юлы белән муниципаль органның кадрлар хезмәте тарафыннан гамәлгә ашырыла.Ачык хакимият органнары һәм тиешле мәгълүматка ия оешмалар соратылган мәгълүматны күрсәтелгән гарызнамә алынган көннән бер айдан да соңга калмыйча бирергә тиеш.»;

1.7. 16 статьяның 3 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) әлеге Нигезләмәнең 15.2 статьясында каралган анкетаны;»;

1.8. 16 статьяның 3 пунктындагы 5 пунктчасында « һәм квалификация турында» сүзләрен өстәргә;

1.9. 16 статьяның 4 пунктында «белешмәләр» сүзеннән соң («анкетадагы белешмәләрдән тыш)» сүзләрен өстәргә;

1.10. 26 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 11.1 һәм 11.2 пунктчаларын өстәргә:

«11.1) 2014 елның 11 маеннан 2022 елның 23 февраленә кадәр Россия Федерациясе гражданлыгын алган һәм шул чорда Донецк Халык Республикасы яки Луганск Халык Республикасы территориясендә даими яшәү вакытына бәйсез рәвештә яшәгән, һәм элегрәк Украина гражданлыгында булган һәм Россия Федерациясе гражданлыгын 2022 елның 24 февраленнән алган Россия Федерациясе гражданнары, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожск өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә гамәлдә булган Украина ССР Конституциясе, норматив хокукый актлар нигезендә төзелгән дәүләт органнарында һәм җирле үзидарә органнарында сайланулы вазыйфаи урыннарда җитәкчеләр, белгечләр булып 1992 елның 1 гыйнварыннан алып 1993 елның 31 декабренә кадәр эшләгән Россия Федерациясе гражданнары;

11.2) әлеге өлешнең 11.1 пунктында күрсәтелгән вазыйфаларны, 1994 елның 1 гыйнварыннан башлап, дәүләт яисә муниципаль вазыйфалар биләгән көнгә кадәр, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы законнары, Запорожск өлкәсе һәм Херсон өлкәсе норматив хокукый актлары яисә Украина законнары нигезендә Россия Федерациясендә дәүләт хезмәтенә яисә муниципаль хезмәткә кергән көнгә кадәр биләгән (Россия Федерациясе законнары нигезендә террорчылык дип танылган хәрби һәм башка формированиеләрдә хезмәт чорларыннан тыш, Россия Федерациясе законнары нигезендә экстремистик дип танылган оешмаларда ирекле әгъзалык чорларыннан тыш, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм аларның халкына каршы хокуксыз гамәлләрдә катнашу

чорларыннан тыш, Россия Федерациясенә каршы Украинаның кораллы көчләре һәм башка формированиеләре составында хәрби гамәлләрдә катнашу чорларыннан тыш),шул исәптән:

а) депутат вазыйфаларында;

б) дәүләт хезмәткәрләре чиннары (ранглары) бирелгән вазыйфаларда;

в) судьялар вазыйфаларында;

г) дипломатик ранглар бирелгән вазыйфаларда;

д) прокуратура хезмәткәрләренең класслы чиннары бирелгән вазыйфаларда;

е) хәрби һәм махсус исемнәр бирелгән вазыйфаларда;

ж) чиннар (ранглар) бирелгән җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларда;

з) Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы дәүләт вазыйфаларында;

и) әлеге органнарның вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итү максатларында кертелгән Запорожск өлкәсенең һәм Херсон өлкәсенең хәрби-гражданлык администрацияләрендә вазыйфаларда;

к) Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы законнары, Запорожск өлкәсе һәм Херсон өлкәсе норматив хокукый актлары яисә әлеге органнарның вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итү максатларында кертелгән Украина законнары нигезендә гавами хакимият органнарында эш итүче башка вазыйфаларда;»;

1.11.31 статьяның 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм муниципаль хезмәт узган вакытта граждан тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне тикшерүне оештыру һәм үткәрү;»;

1.12. 31 статьяга түбәндәге эчтәлекле 11.1 пункт өстәргә:

«11.1) дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларга билгеләнгән формага рөхсәт бирүне рәсмиләштерү;».

2. Әлеге карарны рәсми рәвештә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) Шеңшеңәр авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Кече Лызи авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге башлыгы А.С.Исмагилов